СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

23.09.2019 | с. Нижний Услон | 69-279

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

Түбән Ослан авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү турында

Түбән Ослан авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты нигезендә, Түбән Ослан авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Түбән Ослан авыл җирлеге Советының 16.09.2019 ел, №68-276 «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары, Түбән Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетының 18.09.2009 ел, №499 «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
карар чыгарды:

1. Түбән Ослан авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегендә яшәүче гражданнарга 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза буласызмы?:

- Түбән Ослан авыл җирлеге авылларында юлларга вак таш җәю.

ӘЙЕ ЮК»

3. Әлеге карарны « Волжская новь» район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы

Түбән Ослан авыл җирлеге
Башлыгы А.З.Шайдуллин